# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ

## КАРАР

«22» апреля 2019 ел Бәтке авылы № 2/7

Татарстан Республиксы Тукай муниципаль районы « Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге 10/3 санлы карары белән расланган « Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республиксы Тукай муниципаль районы «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге 7/5 санлы карары белән расланган «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге Нигезләмәнең 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – нигезләмә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе 1 өлеше 3 пункты

нигезендә эшләнгән һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан һөнәри союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәтлегенең гомуми җыелышында катнашу (алга таба - коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең катнашуы) процедурасын регламентлый.».

2.Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Бәтке авыл җирлеге Башлыгы
Совет Рәисе

М.А.Ионычев